# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Тәтеш муниципаль районы составындагы түбәндәге муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп корырга:

1) «Олы Шәмәк авыл җирлеге»н һәм «Кече Шәмәк авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Олы Шәмәк авылы булган «Олы Шәмәк авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

2) «Келәш авыл җирлеге»н һәм «Тоншерма авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Келәш авылы булган «Келәш авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

3) «Лаптевка авыл җирлеге»н һәм «Монастырский авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Монастырский авылы булган «Монастырский авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

4) «Нармонка авыл җирлеге»н һәм «Чинчурино авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Нармонка авылы булган «Нармонка авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

5) «Богдашкино авыл җирлеге»н, «Ивановка авыл җирлеге»н һәм «Урюм авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне

административ үзәге Пролей-Каша авылы булган «Урюм авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән «Олы Шәмәк авыл җирлеге», «Keләш авыл җирлеге», «Монастырский авыл җирлеге», «Нармонка авыл җирлеге», «Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең (алга таба – яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр) беренче чакырылыш вәкиллекле органнары депутатларының һәм беренче башлыкларының вәкаләтләре чорын биш ел дип билгеләргә.

2. Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органнарындагы депутатлар санын ун кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумнарда кабул ителә торган яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарларында башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлек башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 12 (IV өлеш); 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**3 статья.** «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 4 – 35 нче кушымталар) нигезендә билгеләргә, аларга авыл җирлеге статусын бирергә һәм административ үзәкләрен расларга:

Алабирде авыл җирлеге: Алабирде авылы (административ үзәк);

Байраш авыл җирлеге: Байраш авылы (административ үзәк);

Бакырчы авыл җирлеге: Бакырчы (административ үзәк), Үтәмеш, Татар Чагылдымы, Чуаш Чагылдымы, Чуаш Чурапаны авыллары, Татар Чурапаны поселогы;

Бидәңге авыл җирлеге: Татар Бидәңгесе авылы (административ үзәк);

Бессоново авыл җирлеге: Бессоново (административ үзәк), Югары Тархан авыллары;

Зур Әтрәч авыл җирлеге: Зур Әтрәч (административ үзәк), Кече Әтрәч, Никифоровка авыллары;

Олы Тархан авыл җирлеге: Олы Тархан (административ үзәк), Түбән Тархан авыллары, Мәмәй, Төкәш поселоклары;

Олы Тормы авыл җирлеге: Олы Тормы (административ үзәк), Кече Тормы, Чолы авыллары;

Олы Шәмәк авыл җирлеге: Олы Шәмәк (административ үзәк), Кече Бисәр, Кече Шәмәк, Кече Фролово авыллары, Победа поселогы;

Жуково авыл җирлеге: Жуково авылы (административ үзәк), Иоково, Кызыл Тархан, Берлек, Яңа Сумароков авыллары;

Килдеш авыл җирлеге: Килдеш (административ үзәк), Кызыл Күл авыллары;

Киртәле авыл җирлеге: Киртәле (административ үзәк), Кадыш, Васильевка, Красный Восток авыллары;

Келәш авыл җирлеге: Келәш (административ үзәк), Тоншерма авыллары;

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге: Кошки-Новотимбаево (административ үзәк), Яңа Льяшево Пүчинкәсе, Ивановка, Максимовка, Салмановка, Иске Колмәт, Чуаш Тайбасы авыллары;

Льяшево авыл җирлеге: Льяшево (административ үзәк), Олы Бисәр, Ямбакты авыллары;

Монастырский авыл җирлеге: Монастырский (административ үзәк), Лаптевка, Баймәт, Долгая Поляна, Ильинский авыллары;

Нармонка авыл җирлеге: Нармонка (административ үзәк), Зеленовка, Колунец, Чинчурино, Кушкуй авыллары;

Сөендек авыл җирлеге: Сөендек (административ үзәк), Башчы авыллары;

Урюм авыл җирлеге: Пролей-Каша (административ үзәк), Богдашкино, Кашка, Урюм, Ивановка авыллары, Пищемар поселогы;

Федоровка авыл җирлеге: Федоровка (административ үзәк), Алекина Поляна, Удельное Нечасово, Кызыл Йолдыз, Красное Нечасово авыллары.»;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

# "Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керә торган муниципаль берәмлекләрнең чикләре <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
35 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның читтәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 50(3) - 67(4) | - Ульяновск өлкәсе |
| 67(4)-19(36) | - Буа муниципаль районы |
| 2(35)-19(36) | - Апас муниципаль районы |
| 28(34)-2(35) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 50(3)-28(34) | - Спас муниципаль районы |

«Тәтеш муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керә торган
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Тәтеш шәһәре |
| 2 | Алабирде авыл җирлеге |
| 3 | Байраш авыл җирлеге |
| 4 | Бакырчы авыл җирлеге |
| 5 | Бидәңге авыл җирлеге |
| 6 | Бессоново авыл җирлеге |
| 7 | Зур Әтрәч авыл җирлеге |
| 8 | Олы Тархан авыл җирлеге |
| 9 | Олы Тормы авыл җирлеге |
| 10 | Олы Шәмәк авыл җирлеге |
| 11 | Жуково авыл җирлеге |
| 12 | Килдеш авыл җирлеге |
| 13 | Киртәле авыл җирлеге |
| 14 | Келәш авыл җирлеге |
| 15 | Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге |
| 16 | Льяшево авыл җирлеге |
| 17 | Монастырский авыл җирлеге |
| 18 | Нармонка авыл җирлеге |
| 19 | Сөендек авыл җирлеге |
| 20 | Урюм авыл җирлеге |
| 21 | Федоровка авыл җирлеге |

»;

3) 3 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Ивановка,» сүзен төшереп калдырырга, «Нармонка» сүзеннән соң «, Урюм» сүзен өстәргә;

б) дүртенче абзацта «Ивановка һәм Нармонка» сүзләрен «Нармонка һәм Урюм» сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацта «Ивановка» сүзен «Урюм» сүзенә алмаштырырга;

г) сигезенче абзацта «Ивановка» сүзен «Урюм» сүзенә алмаштырырга;

4) 10 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 11 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Лаптевка,» сүзен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацта «Лаптевка» сүзен «Монастырский» сүзенә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Монастырский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәр участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, алга таба шушы инеш агымы буенча 670 м аска таба ул башка инешкә койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча 560 м өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап һәм 200 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң гомуми юнәлештә 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлын кисеп үтеп, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м урман массивы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлына кадәр уза, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 950 м көньякка таба бара, шуннан соң көнбатышка таба борыла һәм 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталына кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,0 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче, 4 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 150 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Зур Әтрәч, Льяшево һәм Монастырский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монастырский авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

6) 13 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «, Кече Шәмәк» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Тормы авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Шәмәк авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм, Чукасы инешен кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тормы елгасына кадәр уза, аннары Тормы елгасы агымы буенча 12,3 км өскә таба инешкә кадәр бара, аннары инеш агымы буенча 2,3 км өскә таба Олы Тормы, Олы Шәмәк авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре

тоташкан урында Кече Фролово авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 14 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Олы Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Олы Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олы Шәмәк авыл җирлеге Олы Тормы, Келәш, Льяшево, Нармонка авыл җирлекләре, Апас һәм Буа муниципаль районнары белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Олы Шәмәк авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Олы Тормы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Шәмәк авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм, Чукасы инешен кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тормы елгасына кадәр уза, аннары Тормы елгасы агымы буенча 12,3 км өскә таба инешкә кадәр бара, аннары инеш агымы буенча 2,3 км өскә таба Олы Тормы, Олы Шәмәк авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кече Фролово авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Льяшево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 560 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, «Апас – Тәтеш» – Олы Шәмәк – Кече Шәмәк автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 1,5 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

Олы Шәмәк, Льяшево һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бисәр авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 810 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Буа – Тәтеш» – Кушкуй автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 1,1 км көнбатышка таба инешкә кадәр уза, шуннан соң инеш агымы буенча 850 м аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, аннары шушы инеш агымы буенча 3,5 км өскә таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталына кадәр уза, 200 м көньяк-көнбатышка таба шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 120 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 50 м көньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 80 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 260 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 880 м көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19 нчы, 20 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап Олы Шәмәк, Келәш һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кушкуй авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Келәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Шәмәк, Келәш авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Победа поселогыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып 630 м көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 400 м шушы урман кварталы буйлап уза, аннары 190 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 м урман массивының төньяк чиге буйлап һәм 610 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,8 км көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 10, 13, 16 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км төньякка таба бара, шуннан соң 240 м төньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 14 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча 2,0 км аска таба бара, аннары гомуми юнәлештә 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең

Тәтеш участок урманчылыгындагы 17 нче урман кварталы чиге буйлап бара, шуннан соң 910 м көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 90 м шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 1,7 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19 нчы, 20 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Олы Шәмәк авыл җирлеге, Апас һәм Буа муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кече Фролово авылыннан 4,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы (36 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Апас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 19 нчы (36 нчы) тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

8) 16 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта «Богдашкино,» сүзен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацта «Богдашкино, Жуково» сүзләрен «Жуково, Урюм» сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Жуково авыл җирлеге чиге Урюм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,5 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап һәм 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кильна елгасына кадәр бара, алга таба бу елга агымы буенча 2,4 км аска таба Жуково, Килдеш һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Берлек авылыннан 980 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

9) 17 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

10) 20 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү һәм<br>аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>20 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Келәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Келәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Келәш авыл җирлеге Олы Шәмәк, Нармонка, Федоровка авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Келәш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Келәш авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә Олы Шәмәк, Келәш авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Победа поселогыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Келәш, Федоровка авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Келәш авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып 630 м көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 400 м шушы урман кварталы буйлап уза, аннары 190 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 м урман массивының төньяк чиге буйлап һәм 610 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,8 км көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 10, 13, 16 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км төньякка таба бара, шуннан соң 240 м төньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 14 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча 2,0 км аска таба бара, аннары гомуми юнәлештә 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 17 нче урман кварталы чиге буйлап бара, шуннан соң 910 м көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 90 м шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш

чиге буйлап һәм 1,7 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19 нчы, 20 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап Олы Шәмәк, Келәш һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кушкуй авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Келәш авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә 5,1 км көньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 20, 24, 26, 30, 36 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Келәш, Нармонка һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 3,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Келәш авыл җирлеге чиге Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып 560 м көньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 35 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

11) 22 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

12) 23 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Льяшево авыл җирлеге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Алабирде, Зур Әтрәч, Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Нармонка авыл җирлекләре белән чиктәш.»;

б) бишенче абзацта «Чинчурино» сүзен «Нармонка» сүзенә алмаштырырга;

в) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Льяшево авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Үләмә елгасына кадәр уза, аннары шушы елга агымы буенча 250 м өскә таба бара, аннары 4,0 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

г) унберенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

13) 26 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 27 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «, Лаптевка авыл җирлекләре» сүзләрен «авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Монастырский авыл җирлеге чиге Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зур Әтрәч, Монастырский авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Лаптевка авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта

урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәр участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, алга таба шушы инеш агымы буенча 670 м аска таба ул башка инешкә койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча 560 м өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап һәм 200 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң гомуми юнәлештә 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлын кисеп үтеп, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м урман массивы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлына кадәр уза, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 950 м көньякка таба бара, шуннан соң көнбатышка таба борыла һәм 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталына кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,0 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче, 4 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 150 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацта «13 нче тоташу ноктасыннан» сүзләрен «3 нче тоташу ноктасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

15) 28 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
28 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Нармонка авыл җирлеге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Олы Шәмәк, Келәш, Льяшево, Урюм һәм Федоровка авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Нармонка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Нармонка авыл җирлеге чиге Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нармонка, Урюм һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 4,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк юнәлештә 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 570 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м урман массивы буйлап, 710 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 210 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 2,7 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 660 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап һәм 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 920 м өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 170 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 1,7 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 210 м төньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, инеш агымы буенча 380 м аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 320 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 900 м төньяк-көнбатышка таба инешне кисеп үтеп бара, шуннан соң 2,4 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 90 м көньяк-көнбатышка таба, 220 м төньяк-көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба, «Буа – Тәтеш» – Удельное Нечасово – Алекина Поляна автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталына кадәр бара, шуннан соң бу урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 310 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 46 нчы, 47 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 1,9 км көньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба уза, аннары «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 700 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,1 км төньяк-көнбатышка таба, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан

Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 37 нче, 36 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап 880 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 36 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 340 м төньяк-көнбатышка таба Келәш, Нармонка һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 3,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нармонка авыл җирлеге чиге Келәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Шәмәк, Келәш һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кушкуй авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә 5,1 км көньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 20, 24, 26, 30, 36 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нармонка авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Шәмәк, Льяшево һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бисәр авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 810 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Буа – Тәтеш» – Кушкуй автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 1,1 км көнбатышка таба инешкә кадәр уза, шуннан соң инеш агымы буенча 850 м аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, аннары шушы инеш агымы буенча 3,5 км өскә таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталына кадәр уза, 200 м көньяк-көнбатышка таба шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 120 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 50 м көньяк-көнчыгышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 80 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 260 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 880 м көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19 нчы, 20 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Нармонка авыл җирлеге чиге Льяшево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Льяшево һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында 23 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Үләмә елгасына кадәр уза, аннары шушы елга агымы буенча 250 м өскә таба бара, аннары 4,0 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нармонка авыл җирлеге чиге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып 300 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 800 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 2,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 450 м көньякка таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, кибеп баручы инешнең агымы буенча 900 м аска таба ул башка инешкә койган җиргә кадәр уза, шул инешнең агымы буенча 1,0 км аска таба инеш Үләмә елгасына койган җиргә кадәр бара, бу елга агымы буенча 200 м аска таба уза, шуннан соң инешнең агымы буенча өскә таба 1,6 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 200 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатыш юнәлештә 150 м аэродромның көнбатыш чиге буенча, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап һәм 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 200 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м урман массивының көнбатыш чиге буенча һәм 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 4,5 км өскә таба уза, Бизә елгасын кисеп үтә, аннары 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең 164 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Нармонка һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кашка авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Нармонка авыл җирлеге чиге Урюм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә 380 м көньяк-көнбатышка таба урман массивы буйлап, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман массивы буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 200 м урман массивы буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, аннары кибеп баручы инешнең агымы буенча 1,3 км өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба һәм 50 м көнбатышка таба 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

16) 31 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 32 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү һәм<br>аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>32 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урюм авыл җирлеге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Жуково, Килдеш, Нармонка, Федоровка авыл җирлекләре, Спас муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының**
**«Урюм авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Урюм авыл җирлеге чиге Килдеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Жуково, Килдеш һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Берлек авылыннан 980 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча 3,6 км өскә таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Тәтеш – Олы Тархан – Ундоры автомобиль юлын кисеп үтеп, 740 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча һәм 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Урюм участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, аннары 1,4 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Урюм участок урманчылыгындагы 2 нче, 4 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буенча Урюмка елгасына кадәр уза, Урюмка елгасы агымы буенча 2,2 км өскә таба бара, шуннан соң гомуми юнәлештә 400 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Урюм участок урманчылыгындагы 12 нче урман кварталына кадәр һәм әлеге урманчылыкның 12 нче, 20 нче урман кварталлары буенча 2,5 км уза, аннары 20 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 710 м көньяк-көнбатыш юнәлешендә бара, шуннан соң 6,8 км көньякка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Урюм участок урманчылыгындагы 30, 41, 54, 65, 74, 83 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буенча Куйбышев сусаклагычының яр сызыгына кадәр уза, аннары, юнәлешен үзгәртмичә, 3,0 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Килдеш, Урюм авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсенең чикләре тоташкан урында Васильевка авылыннан 9,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан X = 346215,94, Y = 1280202,52 координаталы 57 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Урюм авыл җирлеге чиге Жуково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Жуково, Урюм һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 3,8 км көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,5 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап һәм 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кильна елгасына кадәр бара, алга таба бу елга агымы буенча 2,4 км аска таба 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нармонка, Урюм һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 4,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньякка таба һәм, Кызыл Йолдыз – Ивановка автомобиль юлын кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнчыгышка таба 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Нармонка һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кашка авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә 380 м көньяк-көнбатышка таба урман массивы буйлап, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман массивы буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 200 м урман массивы буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, аннары кибеп баручы инешнең агымы буенча 1,3 км өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба һәм 50 м көнбатышка таба 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Урюм авыл җирлеге һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Любимовка авылыннан 6,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан X = 379799,43, Y = 1289326,30 координаталы 25 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә 850 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап яр сызыгына кадәр, 3,9 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 78 нче, 79 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 83 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 1,5 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 850 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 81 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 3,3 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 260 м көньяк-көнбатышка таба 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Урюм авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Урюм авыл җирлеге, Спас муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Пролей-Каша авылыннан 9,0 км көнчыгышта урнашкан X = 365198,68, Y = 1293845,85 координаталы 50 нче (3 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Урюм авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 50 нче (3 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасының административ чиге буйлап 57 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

18) 33 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федоровка авыл җирлеге Жуково, Келәш, Кошки-Новотимбаево, Нармонка, Урюм авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы белән чиктәш.»;

б) бишенче абзацта «Федоровка һәм Чинчурино» сүзләрен «Нармонка һәм Федоровка» сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федоровка авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Нармонка, Урюм һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 4,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк юнәлештә 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 570 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м урман массивы буйлап, 710 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 210 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 2,7 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 660 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап һәм 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 920 м өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 170 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 1,7 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 210 м төньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, инеш агымы буенча 380 м аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 320 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 900 м төньяк-көнбатышка таба инешне кисеп үтеп бара, шуннан соң 2,4 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 90 м көньяк-көнбатышка таба, 220 м төньяк-көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба, «Буа – Тәтеш» – Удельное Нечасово – Алекина Поляна автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталына кадәр бара, шуннан соң бу урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 310 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 46 нчы, 47 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 1,9 км көньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба уза, аннары «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы

дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 700 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,1 км төньяк-көнбатышка таба, «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 37 нче, 36 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап 880 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 36 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 340 м төньяк-көнбатышка таба 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

д) сигезенче абзацта «Богдашкино» сүзен «Урюм» сүзенә, «Богдашкино, Жуково» сүзләрен «Жуково, Урюм» сүзләренә алмаштырырга;

19) 34 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 елның 13 апреле
№ 31-ТРЗ